ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ИСКЕ БОГАДЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423763, Иске Богадыа вылы,
Үзәк ур.,
60нчыйорт.
Тел.:(85552)5-45-30; факс:5-45-30;
E-mail: sbuq-akt@yandex.ru

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ СТАРОБУГАДИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423763, село Старые Бугады,
ул. Центральная, дом 60.
Тел.:(85552)5-45-30; факс:5-45-30;
E-mail: sbuq-akt@yandex.ru

**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ БОГАДЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

**19.12.2019 ел.** **№33**

**2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Актаныш муниципаль районының Иске Богады авыл җирлеге бюджеты турында**

1. 2020 елга Актаныш муниципаль районы Иске Богады авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1.1. Иске Богады авыл җирлеге бюджетының фаразланган гомуми кереме 4232,5 мең сум күләмендә;

1.2. Иске Богады авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 4232,5 мең сум күләмендә.

1.3. Актаныш муниципаль районы Иске Богады авыл җирлеге бюджеты дефицитының иң чик күләме 0 мең сум.

2. Иске Богады авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022 елга бюджет характеристикаларын расларга:

2.1. 2021 елга Иске Богады авыл җирлеге бюджетының фаразланган гомуми кереме 4275,5 мең сум һәм 2022 елга 4232,8 мең сум күләмендә булыр дип фаразлана;

2.2. 2021 елга Иске Богады авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 4275,5 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар күләме 105,8 мең сум һәм 2022 елга 4332,8 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 106,9 мең сум.

2.3. Актаныш муниципаль районы Иске Богады авыл җирлегенең 2021 елга бюджет дефицитының иң чик күләме 0 мең сум һәм 2022 елга 0 мең сум.

3. Иске Богады авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын билгеләргә:

2020 елга һәм 2021 һәм 2022 елларның планлы чорына әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә.

4. 2020 елның 1 гыйнварына Иске Богады авыл җирлегенең эчке муниципаль бурычының югары чиген 0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча югары чикне - 0 мең сум күләмендә билгеләргә.

4.1. 2021 елның 1 гыйнварына Иске Богады авыл җирлегенең эчке муниципаль бурычының югары чиген 0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә билгеләргә.

4.2. 2022 елның 1 гыйнварына Иске Богады авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча эчке муниципаль бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә билгеләргә.

4.3. Иске Богады авыл җирлеге муниципаль бурычының иң чик күләмен билгеләргә:

- 2020 елда - 0 мең сум күләмендә;
- 2021 елда - 0 мең сум күләмендә;
- 2022 елда - 0 мең сум күләмендә.

5. Иске Богады авыл җирлеге бюджетында 2020 елга һәм 2021, 2022 елларның план чорына фаразланган керем күләмен әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә исәпкә алырга.

6. Иске Богады авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә расларга.

7. Иске Богады авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә расларга.

8. Бюджет ассигнованиеләрен 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына классификациянең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре буенча бүлүне әлеге карарның 5 нче кушымтасы нигезендә расларга.

9. 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына бюджет чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарның 6 нчы кушымтасы нигезендә расларга.

10. 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына бюджет ассигнованиеләрен бүлүне әлеге карарның 7 нче кушымтасы нигезендә расларга.

11. 2020 елга ачык норматив йөкләмәләрне үтәүгә - 0 мең сум, 2021 елга - 0 мең сум һәм 2022 елга - 0 мең сум күләмендә бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен расларга.

12. Иске Богады авыл җирлеге бюджетында җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияне алдан каралга:

- 2020 елда 3317,1 мең сум күләмендә, шул исәптән:
  1) бюджет тәэмин ителеше буенча 3308,5 мең сум;
  2) Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән, халык санынан чыгып, 8,6 мең сум күләмендә;
- -2021 елда 3351,4 мең сум күләмендә, шул исәптән:
  1) бюджет тәэмин ителеше буенча 3342,4 мең сум;
  2) Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән, халык санынан чыгып, 9,0 мең сум күләмендә;
- -2022 елда 3399,7 мең сум күләмендә, шул исәптән:
  1) бюджет тәэмин ителеше буенча 3390,7 мең сум;
  2) Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән, халык санынан чыгып, 9,0 мең сум күләмендә;

13. Иске Богады авыл җирлеге бюджетында җирлек бюджетларының баланслылыгы буенча район фондыннан дотацияне алдан каралга;

2020 елда 0 мең сум күләмендә;
2021 елда 0 мең сум күләмендә;
2022 елда 0 мең сум күләмендә;

14. Иске Богады авыл җирлеге бюджетында территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен җирлекләр бюджетларына субвенцияләр күләмен алдан каралга:

- 2020 елга 81,7 мең сум;
- 2021 елга 81,8 мең сум;
- 2022 елга 83,3 мең сум.

15. 2020 елда һәм 2021 һәм 2022 елларның планлы чорында Актаныш муниципаль районы Иске Богады авыл җирлеге бюджетыннан бюджет кредитлары бирелми дип билгеләргә.

16. Иске Богады авыл җирлегенең муниципаль хакимият органнары муниципаль хезмәткәрләр һәм бюджет өлкәсенең башка оешмалары хезмәткәрләре санын арттыруга китерүче, шулай ук аларны тотуга киткән чыгымнарны 2020 елда һәм 2021, 2022 еллар

план чорында кабул итәргә хокуклы түгел.

17. Бюджет үтәгәндә әлеге карар белән расланган керемнәрнең гомуми күләменнән фактта артыграк алынган керемнәр, әлеге карарга үзгәрешләр кертмичә, муниципаль бурычны түләүгә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 217 статьясындагы 3 пунктында каралган күләмдә бюджет ассигнованиеләре җитмәгән очракта, ачык норматив йөкләмәләрне үтәүгә билгеләнгән тәртиптә җибәрелә.

Актаныш муниципаль районы бюджетын үтәгәндә әлеге карар белән расланган керемнәрдән артык фактта алынган субсидияләр һәм субвенцияләр, әлеге карарга үзгәрешләр кертмичә генә, җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертмичә, субсидияләр һәм субвенцияләр бирү максатларына чыгымнарны арттыруга җибәрелә.

18. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Актаныш муниципаль районы Иске Богады авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыралар.

19. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

20. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Актаныш муниципаль районы Иске Богады авыл җирлеге сайтында игълан итәргә.

Иске Богады авыл җирлеге башлыгы И.Ф.Фаттахов.